**Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение**
**«Алманчиковская основная общеобразовательная школа»**
**Батыревского района Чувашской Республики**

Приложение к ООП ООО

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА
# по родному ( татарскому)языку
# на уровне основного общего образования
# (предметная область «Филология»)

Составитель: Абитова Л.М.,
учитель первой квалификационной категории

с. Алманчиково

## 1. ПРОГРАММАНЫ ҮЗЛӘШТЕРҮДӘН КӨТЕЛГӘН НӘТИҖӘЛӘР

**Шәхси нәтиҗәләр (Личностные результаты):**

- татар теленең татар халкы өчен төп милли-мәдәни кыйммәт булуын, ана телендә шәхеснең әхлакый, рухи һәм иҗади яктан формалашудагы ролен аңлау;
- туган телгә мәхәббәт һәм аның белән горурлану хисләре тәрбияләү, туган телне саклау һәм үстерү өлкәсендә эшләргә теләк, омтылыш уяту;
- туган телдә аралашу, үз фикереңне һәм хисләреңне төгәл, анык, күпьяклы итеп белдерү өчен кирәкле булган сүзлек составын һәм грамматик, стилистик чараларны белү;
- аралашу төренә һәм ситуациясенә бәйле сөйләмне куллана һәм үзара бәйли белү;
- иптәшләренең сөйләменә игътибар итү, үзеңнең сөйләмеңә күзәтеп бәя бирү, хаталарны төзәтү, бәхәстә катнашу, төрле дәлилләр кулланып, тема буенча фикер алышу.

Татар телен укытуның **предметара нәтиҗәләре (Метапредметные результаты):**

- татар теленең башка фәннәрне өйрәнү һәм белем алу чарасы икәнен аңлау;
- татар телен әдәбият белән бәйләп, тел чараларының матур әдәбият әсәрләрендәгетәэсир көчен, сәнгатьлелеген булдыруда ролен ачыклау; чор әдәбиятына хас тел-сурәтләү чараларының үзенчәлекләрен ачу;
- телне әдәбият белән бәйләп, укыган яки тыңлаган әсәрнең эчтәлеген, планын, конспектын, резюмесын логик эзлекле итеп язарга, сөйләргә өйрәтү;
- телне мәдәният белән бәйләп, татар теленең байлыгына һәм матурлыгына хөрмәт, зәвык тәрбияләү;
- татар телен рус теле белән бәйләп, телләр һәм халыклар арасындагы уртак хәзинә – рухи кыйммәтләргә ихтирам, башка милләт вәкилләренә карата түземле–ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү; телләрнең үзара бәгланыш-мөнәсәбәтләрен, шул мөнәсәбәтләр нәтиҗәсендә уртак төшенчәләр һәм тел берәмлекләре барлыкка килүне аңлату;
- рус һәм чит телләр, әдәбиятлар белән бәйләп, татар теленең милли-мәдәни үзенчәлекләрен өйрәтү, алган белемнәрне төрле тел күренешләрен аңлатуда куллану;
- телне тарих, җәмгыять белеме фәннәре белән бәйләп, дөнья, кешелек җәмгыяте, аның үсеше турында күзаллау формалаштыру, җәмгыять үсешенең телгә турыдан-туры мөнәсәбәте булуын җиткерү;
- татар теле дәресләрендә алган белем һәм күнекмәләрне телнең кеше һәм җәмгыять тормышында тоткан урынын аңларга ярдәм итү;сөйләмне дөрес куллана, бәяли белергә, үз фикереңнең уңай һәм тискәре якларын аңларга, камилләштерергә өйрәтү;
- әдәби әсәрләрнең теле белән эшләгәндә, татар теле – бәйләүче чараларга бик бай тел, шул чаралар системасын, алар белдергән мәгънәләрне нәтиҗәлерәк үзләштерү максатыннан, стиль мөмкинлекләрен дә исәпкә алып, фикерне төгәл бирердәй сүзтезмә һәм җөмләләрне телебез хәзинәсеннән сайлап ала белү.

**Предметны үзләштерү барышында ирешкән нәтиҗәләр (Предметные результаты):**

Укучылар түбәндәгеләрне үзләштерә:

- сөйләмиятнең барлык төрләрен (тыңлау, аңлау, уку, язу) үзләштерү: язма һәм сөйләм теленә караган мәгълүматның темасын, төп һәм өстәмә фикерен аңлау; төрле стильгә һәм жанрга караган текстларны дөрес уку һәм аңлау; төрле чыганаклардан мәгълүмат туплый белү; сүзлекләрдән һәм электрон чаралардан дөрес файдалана белү; аерым бер темага караган материалны туплый, анализлый, эшкәртә һәм үзгәртә белү;
- татар теленең төп функцияләрен, татар теленең башка төрки телләр арасында тоткан урынын, телнең мәдәният, җәмгыять белән тыгыз бәйләнешен аңлау;
- туган тел турындагы фәнни белемнәрнең нигезен булдыру, тел катламнарының, ярусларының үзара бәйләнешен һәм мөнәсәбәтен аңлау;
- тел белеменең төп төшенчәләрен үзләштерү, аның тармаклары турында мәгълүмат булдыру; тел һәм сөйләм, сөйләм төрләре, аралашу ситуацияләре; сөйләм теле,

функциональ стильләр, матур әдәбият теле; текст һәм аның төрләре; телнең төп берәмлекләре, аларның аермалы билгеләрен, сөйләмдә кулланылу үзенчәлекләрен белү;
- телнең төп стилистик чараларын, телнең әдәби нормаларын, сөйләм әдәбе нормаларын белү, аларны сөйләмдә дөрес кулланырга өйрәнү;
- тел һәм сөйләм берәмлекләрен аера һәм анализлый белү; тел һәм стилистик чараларның кулланылышына бәйле рәвештә сөйләм төрләрен аера һәм чагыштыра белү;
- телнең сәнгати чараларын аеру, аларның эстетик функцияләрен белү.

*Укучыга түбәндәгеләрне үзләштерү мөмкинлеге бирелә:*

- *фонетиканың төрле сәнгатьле уку чараларын аеру;*
- *тамырдаш сүзләр арасындагы мәгънә бәйләнешен һәм чылбырын күрү;*
- *төрле лексик сүзлекләрдән (аңлатмалы, синонимнар, антонимнар, чит тел сүзләре, фразеологик) һәм мультимедия чараларыннан кирәкле мәгълүматны эзләп табу.*
- *публицистик һәм әдәби жанрдагы текстларда морфологик берәмлекләрне тану, фәнни һәм махсус эш стилендә кулланыла торган морфологик формаларны белү;*
- *синтаксик конструкцияләрне функциональ-стилистик үзенчәлекләре ягыннан тикшерү, аларның сөйләмне сәнгатьле итү чарасы булуын аңлау.*

- *сөйләмдә орфографик һәм пунктуацион нормаларны саклауның әһәмиятен күрсәтү;*
- *телдән һәм язма сөйләм арасындагы үзенчәлекләрне аңлый һәм аңлата белә;*
- *телнең халык мәдәнияте һәм тарихы белән аерылгысыз бәйләнештә булуын аерым мисаллар ярдәме белән тасвирлау.*

## 2. ПРОГРАММАНЫҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

**5 класс**

**Татар теле турында гомуми мәгълүмат.**

Телнең аралашу чарасы булуы. Телнең төп функцияләре. Туган телнең һәрбер халык тормышында һәм кешене шәхес итеп формалаштырудагы роле. Кардәш һәм кардәш булмаган телләр. Татарлар яши торган төбәкләр. Телнең кеше тормышында һәм җәмгыятьтә тоткан урыны.

**Фонетика, орфоэпия һәм орфография**

Фонетика һәм орфоэпия турында гомуми төшенчә. Сөйләм органнары, аларның авазларны ясауда катнашуы. Аваз. Фонема. Татар телендә сузык авазлар, аларның саны. Сузык авазларны төркемләү. Татар телендә сузык авазлар өлкәсендәге үзгәрешләр. Сингармонизм законы, аның төрләре. Татар телендә сузыклар кыскару күренеше. Дифтонглар турында төшенчә.

Татар телендә тартык авазлар, аларның саны. Тартык авазларны төркемләү. Тартык авазлар өлкәсендәге үзгәрешләр. Тартык авазларның охшашлануы. Аның төрләре. Татар һәм рус телләрендә сузык авазлар һәм тартык авазлар. [w] һәм [в] тартыклары. [к], [г] һәм[къ], [гъ] тартыклары. ъ һәм ь хәрефләренең дөрес язылышы. [ж] һәм [й], [х] һәм [һ], [н] һәм [ң] авазларын белдерүче хәрефләрнең дөрес язылышы.

**Лексикология һәм сөйләм культурасы.**

Сүз – телнең төп берәмлеге. Сүзнең лексик мәгънәсе. Бер һәм күп мәгънәле сүзләр. Туры һәм күчерелмә мәгънәләр. Антонимнар. Синонимнар. Омонимнар һәм аларның төрләре. Төрки-татар сүзләре һәм алынма сүзләр.

Татар теленең сүзлек составы: искергән сүзләр, тарихи сүзләр һәм неологизмнар, аларның төрләре. Диалекталь лексика, һөнәрчелек лексикасы, терминологик лексика, жаргон сүзләр. Фразеологик әйтелмәләр, аларны мәгънәсе. Фразеологизмнарның сөйләмдә кулланылыш үзенчәлекләре. Татар теленең төп сүзлекләре, аларны куллана белү. Татар теленең төп лексик нормалары. Лексик анализ ясау.

**Морфология**

Сүз төркемнәренең лексик-грамматик төрләре. Сүз төркемнәренең классификациясе. Сүз төркемнәренең үзара мөнәсәбәте. Мөстәкыйль сүз төркемнәре. Исем. Алмашлык. Сан. Сыйфат. Рәвеш. Фигыль. Ярдәмлек сүз төркемнәре, модаль сүз төркемнәре. Аларның семантик, морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләре. Сүз төркемнәренең ясалышы, семантикасы, кулланылыш үзенчәлекләре.

Телнең төп морфологик нормалары. Морфологик анализ ясау.

**Синтаксис һәм пунктуация**

Синтаксис буенча гомуми мәгълүмат. Сүзтезмә һәм җөмлә. Җөмлә турында төшенчә. Әйтү максаты буенча җөмлә төрләре. Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. Гади һәм кушма җөмләләр Җөмлә кисәкләре. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре. Аергыч һәм тәмамлык. Хәлләр.  Җөмләнең тиңдәш кисәкләре. Тиңдәш тәмамлыклар. Тиңдәш хәлләр.

Гади җөмлә төрләре. Җыйнак һәм җәенке гади җөмлә. Тулы һәм ким җөмлә. Сөйләмдә бер составлы җөмләләрнең кулланылыш үзенчәлекләре.

Раслау һәм инкарь җөмлә турында гомуми төшенчә. Туры һәм кыек сөйләм. Диалог, аның язылышы, тыныш билгеләре.

Текст синтаксисы турында гомуми төшенчә. Телнең төп синтаксик нормалары.

Синтаксик анализ ясау.

6 класс

1. **Туган телнең һәрбер халык тормышында һәм кешене шәхес итеп формалаштырудагы роле.**

Телнең кеше тормышында һәм җәмгыятьтә тоткан урынын билгели алу. Татар теле – Татарстан Республикасының дәүләт теле булуын белү. Татар милли әдәби теле. Татар әдәби теленең нормалары турында күзаллау булдыру.

**2. Морфология**

Бүлекнең төп эчтәлеге:Морфология һәм сүз төркемнәре турында гомуми төшенчә. Сүз төркемнәренең лексик-грамматик төрләре, классификациясе. Сүз төркемнәренең үзара мөнәсәбәте.

**3. Мөстәкыйль сүз төркемнәре. Исем**. Исемнең семантик, морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләре.

Бүлекнең төп эчтәлеге:Сүз төркеме буларак исем. Уртаклык һәм ялгызлык исемнәр. Берлек һәм күплек сандагы исемнәр.Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Исемнәрнең тартым белән төрләнеше.Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше.Сан, тартым һәм килеш кушымчаларын куллануда стилистик төрлелек .Исемнәрнең ясалышы, семантикасы.Синоним һәм антоним исемнәр.Исемнәрнең җөмләдә кулланылыш үзенчәлекләре.Исемнәрне гомумиләштереп кабатлау, исемнәргә морфологик анализ ясау.

**4. Сыйфат**

Бүлекнең төп эчтәлеге: Сыйфат турында төшенчә. Сыйфатның семантик, морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләре. Сыйфат дәрәҗәләре (кабатлау).Сыйфатларның ясалышы һәм сыйфат ясагыч кушымчалар.Синоним һәм антоним сыйфатлар.Сыйфатларның исемләшүе һәм җөмләдә кулланылыш үзенчәлекләре.Сыйфатларны гомумиләштереп кабатлау, аларга морфологик анализ ясау.

**5. Рәвеш**

Бүлекнең төп эчтәлеге: Рәвеш турында гомуми төшенчә, аларның җөмләдә кулланылыш үзенчәлекләре. Рәвешнең семантик, морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләре. Рәвешләрнең ясалышы ягыннан төрләре һәм дөрес язылышы. Рәвеш төркемчәләре: саф, охшату-чагыштыру, күләм-чама, урын, вакыт, сәбәп-максат рәвешләре.Рәвеш дәрәҗәләре. Рәвешләрне гомумиләштереп кабатлау, аларга морфологик анализ ясау.

**6. Сан**

Бүлекнең төп эчтәлеге: Сан турында гомуми төшенчә. Санның семантик, морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләре. Гарәп һәм рим цифрлары.Ясалышы ягыннан сан төрләре һәм аларның дөрес язылышы.Сан төркемчәләре: төп, тәртип, бүлем, чама һәм җыю саннары, аларның мәгънәләре һәм кулланылыш үзенчәлекләре.Саннарны гомумиләштереп кабатлау, аларга морфологик анализ ясау.

**7. Алмашлык**

Бүлекнең төп эчтәлеге: Алмашлык турында гомуми төшенчә. Алмашлыкның семантик, морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләре. Алмашлык төркемчәләре.Зат алмашлыклары, аларның килеш белән төрләнеше.Күрсәтү алмашлыклары, аларның килеш белән төрләнеше.Билгеләү алмашлыклары.Сорау алмашлыклары.Юклык һәм билгесезлек алмашлыклары.Тартым алмашлыклары.Алмашлыкларның җөмләдә кулланылыш үзенчәлекләре. Аларны гомумиләштереп кабатлау. Алмашлыкларны морфологик яктан тикшерү.

**8. Фигыль турында төшенчә**. Фигыльнең семантик, морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләре.

Бүлекнең төп эчтәлеге:Фигыль турында төшенчә. Фигыльнең башлангыч формасы. Барлык-юклык төре.Фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Фигыль юнәлешләре.

Фигыль төркемчәләре турында гомуми төшенчә. Затланышлы фигыльләр. Боерык фигыль, аның мәгънәсе һәм зат-сан белән төрләнеше. Боерык фигыльләрдә басым һәм аларны дөрес язу күнегүләре.Хикәя фигыль. Хәзерге заман хикәя фигыльләр, аларның мәгънәләре һәм зат-сан белән төрләнеше.

Үткән заман хикәя фигыльләр, аларның мәгънәләре, формалары һәм зат-сан белән төрләнеше.Киләчәк заман хикәя фигыльләр, аларның мәгънәләре, формалары, зат-сан белән төрләнеше һәм дөрес язылышы.Шарт фигыль, аның мәгънәсе, формалары, зат-сан белән төрләнеше һәм җөмләдә кулланылышы.

Затланышсыз фигыльләр. Сыйфат фигыль, аның мәгънәсе, сыйфат һәм фигыль уртаклыгы. Сыйфат фигыльләрнең заман формалары, аларның хикәя фигыль белән аваздашлыгы. Хәзерге заман сыйфат фигыль. Үткән заман сыйфат фигыль. Киләчәк заман сыйфат фигыль. Хәл фигыль, аның мәгънәләре, төрләре, җөмләдә кулланылышы һәм дөрес язылышы.Исем фигыль, аның мәгънәсе, исем фигыльнең исемгә әйләнүе. Инфинитив, аның җөмләдә кулланылышы һәм дөрес язылышы.Ярдәмче фигыльләр һәм аларның җөмләдә кулланылышы.Мөстәкыйль фигыльләрнең ярдәмче фигыль ролендә йөрүе.Фигыльләрнең ясалыш ягыннан төрләре, семантикасы.Фигыльнең җөмләдә кулланылыш үзенчәлекләре.

Фигыльләрне гомумиләштереп кабатлау, аларга морфологик анализ ясау.

**9. Аваз ияртемнәре**

Бүлекнең төп эчтәлеге: Аваз ияртемнәре турында гомуми төшенчә. Аваз ияртемнәренең семантик, морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләре. Аларның ясалышы, җөмләдә кулланылыш үзенчәлекләре, дөрес язылышы. Аваз ияртемнәреннән ясалган сүзләр. Аваз ияртемнәрен морфологик яктан тикшерү.

10. **Ярдәмлек сүз төркемнәре**. Бүлекнең төп эчтәлеге: Бәйлек турында гомуми төшенчә. Семантик, морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләре. Бәйлекләрнең төркемчәләре .Бәйлек сүзләр, аларның кулланылу үзенчәлекләре.

11. **Теркәгеч. Бүлекнең төп эчтәлеге**:

Теркәгеч турында гомуми төшенчә. Семантик, морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләре. Кулланылыш үзенчәлекләре. Теркәгечләрнең төркемчәләре. Теркәгечләрнең дөрес язылышы.

12. **Модаль сүз төркемнәре**. Кисәкчә. Бүлекнең төп эчтәлеге: Модаль сүз төркемнәре турында гомуми төшенчә. Кисәкчә турында төшенчә.Семантик, морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләре.Кисәкчәләрнең төркемчәләре. Кисәкчәләрнең дөрес язылышы. Кулланылыш үзенчәлекләре.

Бүлекнең төп эчтәлеге:Модаль сүзләр турында гомуми төшенчә. Семантик, морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләре.

13. **Ымлыклар**

Бүлекнең төп эчтәлеге:Ымлыклар турында гомуми төшенчә, аларның мәгънә төркемчәләре. Ымлыкларның дөрес язылышы һәм алар янында тыныш билгеләре.

14. **Морфология буенча үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау.** Телнең төп морфологик нормалары.

Белем-күнекмәләрне куллана белү.

7 класс

1. **Кереш. Сүз төркемнәре.**

Мөстәкыйль сүз төркемнәре. Исемнең, сыйфатның, алмашлыкның,санның,фигыльнең һәм рәвешнең лексик-семантик һәм морфологик-синтаксик үзенчәлекләре. Бәйләгеч һәм модаль сүз төркемнәре, аларның сөйләмдә кулланылышы .Сүз ясалышы.Сүзләрнең мәгънәле кисәкләре. Сүзләрнең сөйләмдәге роле

2.**Синтаксис турында төшенчә**.Сөйләмдә сүзләр бәйләнеше. Тезүле бәйләнеш. Тыныш билгеләре.Тиңдәш кисәкләр янында гомумиләштерүче сүзләр. Тыныш билгеләре.Ияртүле бәйләнеш. Иярүче һәм ияртүче сүз, аларның шартлы билгесе.Ияртүле бәйләнештәге сүзләр арасында хәбәрлекле мөнәсәбәт. Ияртүле бәйләнештәге сүзләр арасында ачыклаулы мөнәсәбәт.Ияртүле бәйләнештәге сүзләр арасында аныклаулы мөнәсәбәт. Ияртүле бәйләнешне кабатлауга күнегүләр эшләү. Синтаксик берәмлекләр.

3. **Сүзтезмә турында төшенчә**. Фигыль сүзтезмә. Сүзтезмәдәге бәйләүче чаралар. Исем сүзтезмә. Сүзтезмәдәге бәйләүче чаралар.

Сыйфат сүзтезмә.Сүзтезмәдәге бәйләүче чаралар.Алмашлык сүзтезмә.

Сүзтезмәдәге бәйләүче чаралар.Сан сүзтезмә. Сүзтезмәдәге бәйләүче чаралар.Рәвеш сүзтезмә. Сүзтезмәдәге бәйләүче чаралар.Хәбәрлек сүз сүзтезмә. Сүзтезмәдәге бәйләүче чаралар. Бифункциональ кушымчалар.Сүзтезмәләрне тикшерү тәртибе.Сүзтезмәләрне гомумиләштереп кабатлау,зачетка әзерләнү.

8 класс

4**. Җөмлә**. Гади җөмлә төрләре. Ике составлы җөмлә.

Бер составлы җөмлә. Сөйләмдә бер составлы җөмләләрнең кулланылыш үзенчәлекләре. Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләре. Хикәя, сорау, боерык җөмләләр.

Тойгылы җөмлә.

Эндәш һәм кереш сүзләр, ымлыклар. Алар янында куела торган тыныш билгеләре.Раслау һәм инкярь җөмләләр.Җыйнак һәм җәенке җөмләләр.Тулы һәм ким җөмләләр.Өстәлмәләр. Гади һәм кушма җөмләләр. Теркәгечле кушма җөмлә.

Теркәгечсез кушма җөмлә.

5. **Җөмләнең баш кисәкләре**.Ия һәм аның белдерелүе.Иянең төрләреХәбәр һәм аның белдерелүе.Хәбәрнең төрләре.

6. **Җөмләнең иярчен кисәкләре**.Аергыч һәм аның белдерелүе.Тәмамлык.

Тәмамлыкның төрләре.Тәмамлыкның төрләре буенча күнегүләр эшләү. Гариза язу.

Хәлләр. Вакыт һәм урын хәлләре. Сәбәп һәм максат хәлләре. Туган як табигатен тасвирлау (пейзаж).Рәвеш һәм күләм хәлләре.Шарт һәм кире хәл.

7. **Аныклагыч**. Аның белдерелүе..

Җөмләнең тиңдәш кисәкләре.

Тиңдәш кисәкләрнең үзара бәйләнеше.Тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре.Тиңдәш һәм тиңдәш түгел аергычлар.

8. **Җөмләнең модаль кисәкләре**. Эндәш сүзләр.Эндәш сүзләр янында тыныш билгеләре.Кереш сүзләр. Керешмәләр. Җөмләдә сүзләр тәртибе. Сүзләрнең туры тәртибе.Сүзләрнең кире тәртибе.Җөмләдә сүз тәртибе һәм логик басым.

9. **Җөмләнең аерымланган кисәкләре**.Җөмләнең аерымланган кисәкләре буенча күнегүләр эшләү..

Аныклагычларның аерымлануы. Аныклагычлар янында тыныш билгеләре.

Аерымланган хәлләр. Аерымланган хәлләр янында тыныш билгеләре.

Җөмләнең аерымланган кисәкләрен гомумиләштереп кабатлау.

Җөмлә кисәкләрен шартлы билгеләр ярдәмендә билгеләп тикшерү.

Җөмлә кисәкләрен шартлы билгеләр ярдәмендә тикшерүгә карата күнегүләр эшләү.

Ике составлы җөмләләргә морфологик-синтаксик анализ ясау.

Бер составлы җөмләләргә морфологик-синтаксик анализ ясау.

Катлауландырылган җөмләләргә морфологик-синтаксик анализ ясау.

Гади җөмләләргә морфологик-синтаксик анализ ясау. Җөмләгә билгеләмә бирү.. Бер составлы җөмләләрне кабатлау. Ике составлы җөмләләрне кабатлау.

**Сөйләм.**

Сөйләм ситуациясе, аның төп компонентлары: адресат һәм адресант, сөйләм шартлары, шәхси аралашу, рәсми аралашу, алдан әзерләнгән сөйләм, әзерлексез сөйләм үзенчәлекләре. Сөйләм шартларына бәйле тел берәмлекләренең кулланылышы. Сөйләм нормалары: фонетик, лексик, морфологик һәм синтаксик нормалар.

**Сөйләм эшчәнлеге буларак текст.** Сөйләмә һәм язма текстлар.Текстның мәгънәви һәм композицион бөтенлеге. Текстның темасы, төп мәгънәсе. Текстның ваграк кисәкләргә бүленеше. Текстның микротемасы. Сөйләмнең мәгънәви төрләре: тасвирлау, бәян итү, фикер йөртү. Текст структурасы. Текстның композицион, жанр төрлелеге. Текстка анализ ясау: темасын ачыклау, төп фикерне билгеләү, стилен билгеләү.

**Телнең кулланылыш ягыннан төрләре**: көнкүреш сөйләм теле, матур әдәбият теле, функциональ стильләр: фәнни стиль, публицистик стиль, рәсми эш кәгазьләре стиле, хәзерге электрон чаралар теле. Фәнни стиль төрләре: реферат, чыгыш, доклад, мәкалә, бәяләмә. Публицистик стиль төрләре: чыгыш, интервью, очерк, мәкалә. Рәсми эш кәгазьләре стиле төрләре: ышанычнамә, гариза, резюме, портфолио. Сөйләм теле төрләре: хикәя, әңгәмә, бәхәс.

**Тел системасы**

9 класс

**Татар теле турында гомуми мәгълүмат.**

Телнең аралашу чарасы булуы. Телнең төп функцияләре. Туган телнең һәрбер халык тормышында һәм кешене шәхес итеп формалаштырудагы роле.

Кардәш һәм кардәш булмаган телләр. Татарлар яши торган төбәкләр.

Телнең кеше тормышында һәм җәмгыятьтә тоткан урыны.

**Синтаксис**

Кушма җөмлә турында төшенчә. Кушма җөмлә төрләре. Тезмә кушма җөмлә. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр.

Иярченле кушма җөмлә турында төшенчә. Татар һәм рус телләрендә иярченле кушма җөмләнең төзелеше. Синтетик иярченле кушма җөмлә, аның бәйләүче чаралары, тыныш билгеләре. Аналитик иярченле кушма җөмлә, аның бәйләүче чаралары, тыныш билгеләре.

Иярчен җөмлә һәм аның төрләре. Катлаулы кушма җөмләләр.

Текст синтаксисы турында гомуми төшенчә. Телнең төп синтаксик нормалары. Синтаксик анализ ясау.

**Сөйләм культурасы**

Язма тел һәм сөйләмә тел төшенчәләре. Сөйләмдә синонимнарны, антонимнар һ.б. тел чараларын дөрес куллану. Әдәби телне, сөйләм культурасын үстерүдә һәм стильне камилләштерүдә синтаксик синонимнарның роле.

Сөйләм культурасы төшенчәсе. Әдәби сөйләмгә куелган таләпләр турында гомуми мәгълүмат. Сөйләмдә лексик чараларның (синонимнар, антонимнар, калькалар, фразеологизмнар, мәкаль һәм әйтемнәр) кулланылыш мөмкинлекләре.

**Пунктуация.**

Татар телендә тыныш билгеләре. Ия белән хәбәр арасына сызык кую очраклары. Хәл, аныклагыч, эндәш һәм кереш сүзләр янында тыныш билгеләре. Тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре.

Диалог, аның язылышы, тыныш билгеләре. Туры сөйләм янында тыныш билгеләре.

Кушма җөмлә янында тыныш билгеләре.

**Тел һәм мәдәният**

Татар сөйләм әдәбе. Аралашуның төренә бәйле сөйләм әдәбен куллану.

Сүздә, текстта милли-мәдәни мәгънәгә ия берәмлекләрне таба һәм аңлатмалы, этимологик, фразеологик һ.б. сүзлекләр ярдәмендә мәгънәләрен аңлату.

## 3.Татар теленнэн тематик планнар (5-9 класс)

### 5 нче сыйныф татар теленнән тематик план

| № | Дәрес темасы | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Татар теле турында гомуми мәгълүмат. | 3 |
| 2 | Фонетика орфоэпия һәм орфография. | 7 |
| 3 | Лексикология һәм сөйләм культурасы. | 15 |
| 4 | Морфология. Контроль диктант. | 21 |
| 5 | Синтаксис һәм пунктуация. Контроль диктант. | 24 |
| | | 70 |

### 6 нчы сыйныф татар теленнән тематик план

| № п/п | Тема | Количество часов |
|---|---|---|
| 1 | Кереш. | 1 |
| 2 | Сүз төркемнәре турында гомуми төшенчә. | 4 |
| 3 | Мөстәкыйль сүз төркемнәре. Исем. | 6 |
| 4 | Сыйфат. | 6 |
| 5 | Рәвеш | 6 |
| 6 | Сан. Контроль диктант. | 5 |
| 7 | Алмашлык. | 8 |
| 8 | Фигыль | 15 |
| 9 | Аваз ияртемнәре | 2 |
| 10 | Хәбәрлек сүзләр. | 4 |
| 11 | Теркәгеч. Контроль диктант. | 2 |
| 12 | Модаль сүз төркемнәре | 6 |
| 13 | Ымлыклар | 2 |
| 14 | Кабатлау. | 3 |
| | | 70сэг |

**7 нче сыйныф татар теленнән тематик план**

| № п/п | Тема | Кол-во часов |
|---|---|---|
| 1. | Кереш. Сүз төркемнәре. | 5 |
| 2. | Синтаксис турында төшенчә. | 6 |
| 3. | Сүзтезмә турында төшенчә. | 7 |
| 4. | Җөмлә. Контроль диктант. | 15 |
| 5. | Җөмләнең баш кисәкләре. | 5 |
| 6. | Җөмләнең иярчен кисәкләре. | 12 |
| 7. | Аныклагыч. Аның белдерелүе. | 6 |
| 8. | Җөмләнең модаль кисәкләре. Контроль диктант. | 6 |
| 9. | Җөмләнең аерымланган кисәкләре. | 8 |
| | | 70сэг |

**8нче сыйныф татар теленнэн тематик план**

| **№** | ***Дәреснең темасы*** | ***Сәг.саны*** |
|---|---|---|
| 1 | Кабатлау. Тел һәм тел гыйлеме. | 1 |
| 2 | Туры һәм кыек сөйләм | 7 |
| 3 | Кушма җөмлә . | 8 |
| 4 | Иярченле кушма җөмлә | 10 |
| 5 | Иярчен җөмлә һәм аның төрләре. | 12 |
| 6 | Күп иярченле кушма җөмлә турында төшенчә. | 12 |
| 7 | Җөмләнең мәгънәсе, төзелеше, интонация һәм тыныш билгеләре | 8 |
| 8 | Гади һәм кушма җөмләләр. | 5 |
| 9 | Синтаксисны гомумиләштереп кабатлау. | 7 |
| | | **70 сэг** |

**9нчы сыйныф татар теленнэн тематик план**

| № | Тема | Сэгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Фонетика | 4 |
| 2 | Лексикология | 6 |
| 3 | Сүз төркемнәре. | 10 |
| 4 | Синтаксис һәм пунктуация | 15 |
| 5 | Стилистика һәм сөйләм культурасы | 20 |
| 6 | Тел – иҗтимагый күренеш. Тел үсеше турында гомуми мәгълүмат. Татар әдәби теленең үсеше. | 15 |
| | | 70 сэг |